РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЙДАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

Ленина ул., д. 39, д.Айдарово, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЙДАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин ур., 39 нче йорт, Айдар авылы, 422095
тел. (факс): (84360) 5-34-46,
E-mail: Aydar.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318091 ОГРН 1061675010825 ИНН/КПП 1619004436/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабрь 2025 ел № 32

**Айдар авыл җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрне (фейерверк күрсәтүләр) куллануны тәртипкә салу чаралары турында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Һава киңлегеннән файдалануның Федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы, «Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында»2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарлары нигезендә, халыкның гомерен һәм сәламәтлеген яклау, муниципаль мөлкәткә, юридик һәм физик затлар мөлкәтенә зыян китерүгә юл куймау максатларында, Теләче муниципаль районы Айдар авыл җирлеге Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Айдар авыл җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрне (фейерверк күрсәтүләр) (алга таба - фейерверк) куллану мәйданчыкларын әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. Фейерверклар куллануны тыярга:

- теләсә кайсы функциональ билгеләнештәге бүлмәләрдә, биналарда һәм корылмаларда, шул исәптән әйләнә-тирә территорияне дә кертеп;

- шартлау куркынычы булган һәм янгын куркынычы янаган объектлар, җитештерү предприятиеләре территорияләрендә, тимер юлларны, нефть үткәргечләрне, газүткәргечләрне, югары вольтлы электр тапшырулары линияләрен аерып алу полосаларында, вокзалларда, аэропортларда, хәрби билгеләнештәге объектларда, барлык җәмәгать транспорты төрләрендә, шулай ук әлеге объектлар чикләреннән 500 м дан якынрак булмаган урыннарда;

-балалар, уку, дәвалау-профилактика һәм фәнни учреждениеләр янындагы территорияләрдә, шулай ук әлеге объектларның чикләреннән 50 м ким булмаган аралыкта;

- түбәләрдә, балконнарда, лоджияләрдә, биналарның (корылмаларның) алгы өлешләрендә, сәхнә мәйданчыкларында, стадионнарда һәм башка спорт корылмаларында;

- митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре, пикетлар уздыру вакытында;

- пиротехник эшләнмәләр җитештерүче тарафыннан билгеләнгән яшь чикләүләренә ирешмәгән затларга;

- 2013 елның 26 декабрендәге «Гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны саклау турында» 102-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төнге вакытта.

3. Айдар авыл җирлеге территориясендә биеклеккә ачык ут ярдәмендә корылма эчендәге һаваны җылытуга нигезләнгән, яна торган материаллардан ясалган, идарә ителми торган эшләнмәләрне җибәрүне тыярга;

3. Әлеге карарга 1 номерлы кушымтада билгеләнгән мәйданчыкларда III һәм аннан да югарырак куркынычлылык класслы пиротехник эшләнмәләр кулланып, фейерверклар әзерләгәндә һәм кулланганда:

- фейерверк үткәрү мөмкин булган техник чишелешләр (шартлар) эшләнергә тиеш. Алар фейерверк эшләнмәләрен урнаштыру пунктлары билгеләнгән җирлек схемасын, куркынычсыз зона чикләрен күрсәтеп корылмаларга кадәр куркынычсыз араларны, шулай ук саклау урыннарын үз эченә алырга тиеш;

- янгын куркынычсызлыгының билгеләнгән таләпләренә туры килү-килмәү турында бәяләмә, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә аккредитациясе булган теләсә кайсы оешмада фейерверк үткәрү өчен тәкъдим ителгән документларга туры килү-килмәү турында бәяләмә алынырга тиеш;

- фейерверкны оештыру һәм ату мәйданчыгы әлеге карарның 2 номерлы кушымтасында бирелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

5. Әлеге карарның 2, 3 пунктларында күрсәтелгән шартларны үтәгәннән соң, фейерверк куллану өчен Айдар авыл җирлеге Башкарма комитетында рөхсәт алу кирәк. Айдар авыл җирлеге Башкарма комитетының язмача

рөхсәтеннән башка авыл җирлеге территориясендә фейерверк куллану тыела.

6. Киңәш ителәә:

6.1. Татарстан Республикасы буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының төп идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсе Саба һәм Теләче муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр буенча муниципальара бүлегенә (алга таба - ОНД һәм ПР):

- үз вәкаләтләре кысаларында халыкка массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка мәгълүмат каналлары аша Айдар авыл җирлеге территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары турында хәбәр итүдә, шулай ук янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә пропаганда алып баруда катнашырга;

- гамәлдәге законнар кысаларында әлеге карарның 1 номерлы кушымтасында күрсәтелгән оештырылган мәйданчыкларда фейерверк җибәрү урыннарының әзерлеген тикшерүне оештырырга.

6.2. Теләче районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә ОНД һәм ПР белән үзара хезмәттәшлек кысаларында һәм Айдар авыл җирлеге Башкарма комитеты белән берлектә Айдар авыл җирлеге территориясендә рөхсәтсез фейерверк җибәрүләрне туктату өчен кирәкле ярдәм күрсәтергә.

7. Айдар авыл җирлеге башкарма комитетының 25.12.2024 ел № 24 « Айдар авыл җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрне (фейерверк күрсәтүләр) куллануны тәртипкә салу чаралары турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Теләче муниципаль районының Айдар авыл җирлеге рәсми сайтында http://tulachi.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

Авыл җирлеге башлыгы Х.Ш.Хәсәншин

1 номерлы кушымта
Теләче муниципаль районы Айдар авыл
җирлеге башкарма комитетының «25» декабрь 2025 ел
№ 32 карары белән расланган

Айдар авыл җирлегендә пиротехник эшләнмәләрне куллану (фейерверк күрсәтүләр) мәйданчыклары

1. Айдар ав. «Сабантуй» милли бәйрәме үткәрү территориясендә;
2. Субаш ав. «Сабантуй» милли бәйрәме үткәрү территориясендә;

Яңа ел бәйрәмнәре көннәрендә авыл җирлеге халкы өчен фейерверклар куллану мәйданчыклары Айдар авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә. Башка мәйданчыклар контроль органнары белән килешеп, әмма әлеге карарның 2 - 4 пунктларын үтәгәндә генә.

2 номерлы кушымта
Теләче муниципаль районы Айдар авыл
җирлеге башкарма комитетының «25» декабрь 2025 ел
№ 32 карары белән расланган

Айдар авыл җирлегендә пиротехник эшләнмәләрне куллану (фейерверк күрсәтүләр) мәйданчыгына таләпләр

1. Фейерверк үткәрү мәйданчыгы коймаланырга һәм беренчел янгын сүндерү чаралары белән җиһазландырылырга тиеш.
2. Анда куркынычсыз зона чикләрен, шулай ук эшләнмәләрне саклау урыннарын күрсәтеп, биналарга һәм корылмаларга кадәр Куркынычсыз араларны күздә тотып, фейерверк урнаштыру пунктлары билгеләмәләрен төшерү схемасы үтәлгән булырга тиеш (схема А1 форматыннан ким булмаган күләмдә).
3. Тамашачылар җил ягыннан булырга тиеш. Пиротехник эшләнмәләр урнаштыру схемасы буенча җил тизлеге 10 м/с артмаска тиеш. Фейерверк үткәрү урыннарыннан биналарга һәм тамашачыларга кадәр куркынычсыз ара кулланылган пиротехник эшләнмәләр инструкциясе таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.
4. Мәйданчыкларда тәмәке тарту һәм ут кабызу, шулай ук пиротехник эшләнмәләрне караучысыз калдыру тыела.
5. Пиротехник эшләнмәләрдән файдаланганнан соң, территория тикшерелергә һәм эшкәртелгән, пиротехник эшләнмәләрдән һәм аларның куркыныч элементларыннан чистартылырга тиеш.
6. Фейерверклар урнаштырганда урыннарны саклау һәм куркынычсызлык өчен җаваплылык фейерверк үткәрүче затка (оешмага) йөкләнә.
7. Мәйдан территориясе, шулай ук мәйдан чикләреннән 30 м радиуста территория елның теләсә кайсы вакытында ягулык материалларыннан чистартылырга тиеш.